Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ Карар

02.02.2022 Менделеевск ш. 62

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы территориясендә
торак булмаган бинаны һәм корылманы
эксплуатацияләү өчен яраклы түгел,
авария хәлендә һәм җимерелергә яисә
реконструкцияләнергә тиешле дип тану
мәсьәләләрен карау буенча ведомствоара
комиссия составын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, торак булмаган бинаны һәм корылмаларны эксплуатацияләүгә яраксыз (яраклы), авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тануның бердәм тәртибен куллану максатларында Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты
КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы территориясендә торак булмаган бинаны һәм корылманы эксплуатацияләү өчен яраксыз (яраклы), авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану мәсьәләләрнен карау буенча ведомствоара комиссия составын кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru «Норматив документлар» бүлегендә урнаштырырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http//pravo.tatarstan.ru бастырырга.

3. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының «Ведомствоара комиссиясе турында һәм торак булмаган бинаны һәм корылманы эксплуатацияләү өчен яраксыз (яраклы) дип тану нигезләмәсен раслау хакында» 2019 елның 14 августындагы 440 номерлы карарның 1 нче кушымтасы үз көчен югалткан дип санарга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм инфраструктур үсеш буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.И.Беляев

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның 2 февралендәге
62 номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы территориясендә торак булмаган бинаны һәм корылманы эксплуатацияләү яраксыз (яраклы), авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану мәсьәләләрен карау буенча ведомствоара комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Рәис | - Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм инфраструктура үсеше буенча беренче урынбасары |
| Сәркатип | - Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы |
| әгъзалары | - Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының мөлкәти һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе (килешү буенча); |
| | - «Менделеевск муниципаль районының инвестиция һәм инфраструктура үсеш идарәсе» башлыгы;<br>- Менделеевск муниципаль районының инвестиция һәм инфраструктура үсеше идарәсе» проектлау бүлеге башлыгы;<br>- ТР ТИБ АҖ Менделеевск бүлекчәсе җитәкчесе (килешү буенча);<br>- Алабуга һәм Менделеевск районнарында кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең территориаль бүлеге башлыгы (килешү буенча);<br>- Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенең күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эш идарәсенең Менделеевск муниципаль районы буенча күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эш бүлеге башлыгы (килешү буенча);<br>- Татарстан Республикасы дәүләт торак инспекциясе башлыгы урынбасары - Алабуга зонасы торак инспекциясе башлыгы (килешү буенча);<br>- ТР экология һәм табигый ресурслар министрлыгының Кама буе территориаль идарәсе башлыгы (килешү буенча);<br>- Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының авыл җирлекләре башлыклары (килешү буенча) |